Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы
Красный Бор авыл җирлегенең Красный Бор торак пунктында
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2019 елның 10 декабре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Красный Бор авыл җирлегенең Красный Бор торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1. « I һәм II төркем инвалидлары, өлкән яшьтәге гражданнар (80 яшькә җиткән), көндезге формада белем алучы студентлар, раслаучы документлары булган очракта, ирекле халык дружинасы әгъзалары, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан тыш, 2020 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Красный Бор авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган, 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендәге территорияне төзекләндерү:
- Кызыл Бор авылы урамнарын кардан чистарту
- Кызыл Бор авыллары зираты территориясен төзекләндерү
- гомуми файдаланудагы юлларны ремонтлау, вак таш җәю.
- урамнарны яктырту өчен лампалар сатып алу.
- Кызыл Бор авылында балалар мәйданчыгы төзү, балалар өчен уен комплекслары сатып алу һәм урнаштыру;
- Кызыл Бор авылында тротуарлар төзү
- санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Красный Бор авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм http://agryz.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Муниципаль берәмлек башлыгы А.Н. ЛАЗАРЕВ